**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 25 декабрендәге 5345 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкаручы мәгълүмати-методик бүлекләрдәге хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 22 ноябрендәге под-1950/24 номерлы «2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы “Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү өчен тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында”гы әмергә үзгәрешләр кертү турында»гы әмеренә таянып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 июлендәге 2335 номерлы, 2024 елның 4 октябрендәге 4198 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлекләрдә муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең II бүлегендәге 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе структурасына караган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айга төп оклад күләме, сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Төп гомуми белем, урта гомуми белем** | **Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем** | **Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен бирү белән раслана торган югары белем** |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20246,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 20251,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>структур бүлекчә: муниципаль | - | - | 20329,0 |

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айга төп оклад күләме, сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Төп гомуми белем, урта гомуми белем** | **Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем** | **Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясен бирү белән раслана торган югары белем** |
| | берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы) | | | 20405,0» |

1.2. Нигезләмәгә кушымтаның «Стимуллаштыру сыйфатындагы түләү бирү өчен нигез булып торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 1.13 пунктча белән тулыландырырга:

| № т/б | Мактаулы исем, бүләк атамасы |
|---|---|
| «1.13 | “Яшьлек һәм һөнәри осталык” күкрәк билгесе» |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**